# КОТЛАУЛАР

## ИКЕНЧЕ КИТАП

Авторы
*Гөлфия Шакирова*

Казан
«Халкыбыз мирасы»
2015

ББК 84(Рос=Тат)
УДК 821.161.1
Ш17

**Гөлфия Шакирова**
Ш17 Котлаулар. Икенче китап – Казан: «Халкыбыз мирасы» нәшрияты, 2015. – 80 б.

© «Халкыбыз мирасы», 2015

ISBN 978-5-905160-06-6

# ЭЧТӘЛЕК

## Туй котлаулары

1. ТУЙЛАР МӨБАРӘК БУЛСЫН!...............6
2. КӘЛӘШ..........................................................7
3. РОЗА ЧӘЧӘГЕ КӨНЕ ...............................8
4. 10 ЕЛ БЕРГӘ ЯШӘГӘЧ.............................9
5. СЕЗНЕҢ КЕБЕГЕ СИРӘК.......................11
6. КЫЗЫЛ ТУЙ..............................................12
7. КАВЫШУ КӨНЕ.......................................13
8. ТУЙЛАР МӨБАРӘК БУЛСЫН.............15
9. КОТЛЫ БУЛСЫН ТУЙЛАРЫГЫЗ.......16
10.БӘХЕТЛЕ БУЛЫГЫЗ!............................17

## Әти-әниләргә

11. «ӘНИ» ДИП ЙӨРӘККӘ ЯЗЫЛГАН....18
12. СҮЗЛӘРЕҢ ДӘВА.................................19
13. РӘХМӘТ ӘТИ, РӘХМӘТ, ӘНИ!.........20
14. СЕЗ ҺАМАН МИҢА КИРӘК...............21
15. ӘНИЕМ КӨТӘ.........................................22
16. ИСӘНЛЕГЕҢ КЫЙММӘТ БАРЫННАН......................................23
17. ӘНИЕМНЕҢ НАЗЛЫ КҮҢЕЛЕ..........24

18. ТӨШЛӘРЕМДӘ ЮАТ, ӘНИЕМ...........25
19. СИН КАЙДА ИДЕҢ, ӘТИЕМ..............26
20. ӘТИЕМНЕҢ ТУГАН КӨНЕ..................27
21. ӘНИЕМ, СИНЕ ЗУРЛЫЙБЫЗ.............28
22. «ӘТИ» ДИЕП ӘЙТӘ АЛМАДЫМ.....29
23. ӘТИ-ӘНИЕМӘ...........................................30
24. ТУГАН КӨНЕҢ – ЮБИЛЕЕҢ БЕЛӘН, ӘНИЕМ...............................................31
25. ИСӘН ГЕНӘ БУЛ, ӘНИЕМ..................32
26. БӘЙРӘМ БУЛСЫН ҺӘР КӨНЕГЕЗ ..33
27. ӘТИ-ӘНИ ФАТИХАСЫ.......................34
28.СИНЕҢ КЕБЕК ЯШИ АЛСАМ ............35
29. СӨЙЛӘШИК ӘЛЕ, ӘНИЕМ.................36
30. ИСӘН-САУ ГЫНА БУЛЫГЫЗ!...........37
31. ӘТКӘЙ-ӘНКӘЙГӘ РӘХМӘТ!..............38
32. РӘХМӘТ ӘТКӘЙ-ӘНКӘЙГӘ...............39
33. УТЫР, ӘНИЕМ, СӨЙЛӘШИК... ........40
34. УТЫР ӘЛЕ, ӘНИ, ЯННАРЫМА.........41
35. АК ТЕЛӘК...................................................42
36. ЫШАН, ӘНИЕМ.......................................43
37. БИК САГЫНАМ, ӘНИЕМ...................44
38. САГЫНДЫМ, ӘНИЕМ.........................45
39. МАТУР ПАР..............................................46
40. ОНЫТМАГЫЗ ӘТИ-ӘНИЛӘРНЕ!.....47
41. АНА КӨТӘ СОЛДАТ УЛЫН...............48

42.ШАТЛАНДЫРЫЙМ НИЧЕК?..............49
43. ЯРАТАМ ӘНИЕМНЕ.............................50
44. РӘХМӘТ, ӘТИЕМ!.................................51
45. ӘНИЕМӘ....................................................52
46. ЯШӘГЕЗ ШАТЛЫКТА..........................53
47. БИК КАДЕРЛЕ СЕЗ МИҢА..................54
48. ӘТИЕМНЕ КӨТӘ ӘНИЕМ...................56
49. ӘНИЕМӘ.....................................................58
50. РӘХМӘТ, ӘНИЕМ!.................................59
51. МӘҢГЕ ЯШЬ КАЛ, ӘНИЕМ................61
52. АНА ЙӨРӘГЕ..........................................62
53.МЕҢ-МЕҢ РӘХМӘТ!..............................63

**Дүртьюллыклар**............................................64

# Туй котлаулары

## 1. ТУЙЛАР МӨБАРӘК БУЛСЫН

Тормышларны җыр иткәнгә,
Мәхәббәткә мең рәхмәт!
Язмышларны бергә куша,
Кавыштыра мәхәббәт.

Котлы булсын, котлы булсын,
Туйлар мөбарәк булсын!
Саф сөюнең хисләреннән
Бәхетегез ташып торсын.

Котлап сезне чын күңелдән,
Ява теләк бәйләме.
Изге сәгатьләрдә булсын
Сезнең тормыш бәйрәме.

Бу сөюләр, бу мәхәббәт
Җитсен сезнең гомергә.
Куанычны ике итеп,
Гомер итегез бергә!

## 2. КӘЛӘШ

Матурлардан да матур,
Чибәрләрдән дә чибәр.
Туй күлмәге кигән кызны
Бездә бит «кәләш», диләр.

Ак бөркәнчек, ап-ак күлмәк –
Бик килешә йөзеңә.
Яратып бар да эндәшә,
Кәләш, диеп үзеңә.

Бик күп кызларның хыялы –
Бәхетле кәләш булу.
Сөйгәнеңнең кочагында
Син бүген бигрәк сылу.

Син гүя гүзәл аккоштай
Мәхәббәтнең күлендә.
Якты йолдыздай балкыйсың
Сөюләрнең күгендә.

## 3. РОЗА ЧӘЧӘГЕ КӨНЕ

*(10 ел бергә)*

Сезнең бергә яшәгәнгә
Ун ел тулган көнегез.
Гел дә шулай шатлык белән
Үтсен лә гомерегез.

Ун ел тулган көнне, диләр,
Роза чәчәге көне.
Шушы гүзәл бәйрәм белән
Котлыйбыз менә сезне.

Роза бит ул, роза гөле,
Ул – гашыйклар чәчәге.
Сезнең кебек матур парның
Гөл булыр киләчәге.

Тормышыгыз тату, күркәм,
Табыныгыз түгәрәк.
Ун ел гаилә бәйрәмегез
Булсын матур, мөбарәк.

Бар туганнар котлар өчен
Җыелдык без табынга.

Бер-берегезне кадерләп,
Яшәгезче тагын да.

## 4. 10 ЕЛ БЕРГӘ ЯШӘГӘЧ

Сизелми лә уза гомер,
Инде сез ун ел бергә!
Рөхсәт итегез иң матур
Теләкләрне әйтергә.

Күз алдында шундый матур
Гаилә төзедегез.
Сезгә кайчан килсәк тә без,
Кояш кебек йөзегез.

Тормышыгыз таза, матур,
Һәрнәрсәгез җитешкән.
Син бит, энем, тәм табасың
Һәрбер эшләгән эштән.

Килен дә бит безнең уңган,
Аш-суга да бик булган.
Һәрвакытта диям сезгә:
Юлыгыз булсын уңнан!

Рәхмәт сезгә, туганнарны
Бик тә якын итәсез.
Олы җанлы, мәрхәмәтле,
Чын кешеләр икәнсез.

Бәхет-шатлык, куанычлар
Бирсен озын гомерне.
Энем ... , килен ... ,
Сез безгә бик кадерле!

Сокланабыз сезгә карап,
Сез бит безнең горурлык.
Үрнәк, матур яшәвегез
Ул бит үзе – батырлык!

## 5. СЕЗНЕҢ КЕБЕГЕ СИРӘК

Язмыш сезне очраштырган,
Сез бит шуңа танышкан.
Вакытында табышкан да
Вакытында кавышкан.

Берегез – ай, бер(е)гез – кояш,
Гомергә бергә, дигән.
Сезнең кебек сирәк була
Бер-берсен өз(е)леп сөйгән.

Һәрвакытта бер-береңә
Булыгыз ныклы терәк.
Тоеп бәхет мизгелләрен
Типсен сезнең пар йөрәк.

Сандугачлардай сайрашып,
Күгәрчендәй гөрләшеп
Үткәрегез гомерләрне,
Бергә-бергә серләшеп!

## 6. КЫЗЫЛ ТУЙ

Алтын туйлар, алтын туйлар,
Була бит ул бер генә.
Әткәй-әнкәй, яшәдегез
Үрнәк булып гомергә.

Котлап алтын туегызны,
Нинди сүзләр табаем?
Озын гомер, сәламәтлек
Бирсен сезгә Ходаем!

Алтын туегызны котлап,
Кояш та бүген көлә.
Картаймыйча яшь торыгыз,
Әткәй-әнкәй, гомергә!

Рәхмәтләрем чиксез минем,
Баш иям алдыгызда.
Хәсрәт күрми яшәгез, дип
Әйтәбез барыбыз да!

## 7. КАВЫШУ КӨНЕ

Гүзәл яшьлекнең
Олы бәйрәме.
Истә калырлар
Кавышу көннәре.

Аклык-сафлыкка
Үрелеп үссен
Сез утырткан
Тормыш гөлләре.

Матур теләкләр
Телибез сезгә.
Атлагыз икәү
Гомер-гомергә.

Менәсе юллар
Авыр, катлаулы.
Җиңәргә тиеш
Икәү сез аны!

Барыбыз бергә,
Нык терәк булып,

Көтик дөньяны,
Көтик дөньяны.

Корычтай булсын
Биргән вәгъдәләр.
Кояштай озын
Булсын гомерләр.

Саф сөю белән
Типсен йөрәкләр.
Бездән сезләргә
Иң саф теләкләр.

## 8. ТУЙЛАР МӨБАРӘК БУЛСЫН!

Тормышларны җыр иткәнгә
Мәхәббәткә мең рәхмәт!
Язмышларны бергә куша,
Кавыштыра мәхәббәт.

Котлы булсын, котлы булсын,
Туйлар мөбарәк булсын!
Саф сөюнең хисләреннән
Бәхетегез ташып торсын.

Котлап сезне чын күңелдән,
Ява теләк бәйләме.
Изге сәгатьләрдә булсын
Сезнең тормыш бәйрәме.

Бу сөюләр, бу мәхәббәт
Җитсен сезнең гомергә.
Куанычны ике итеп
Гомер итегез бергә!

## 9. КОТЛЫ БУЛСЫН ТУЙЛАРЫГЫЗ

Туйлар гөрли – яшьлек туе,
Телибез изге теләк.
Мәхәббәттән ялкынланып
Типсен лә сезнең йөрәк.

Бәхет-шатлыкка, диябез,
Гел яхшыга юрыйбыз.
Котлы булсын туйларыгыз,
Ачык булсын юлыгыз!

Бәхетегез булсын сезнең
Һәрвакытта бербөтен.
Аклагыз сез гомерләрдә
Бер-бер(е)гезнең өметен.

Бәхеткә-шатлыкка, диеп
Телибез теләкләрне.
Изге һәм дә матур уйлар
Бейләсен йөрәкләрне.

## 10. БӘХЕТЛЕ БУЛЫГЫЗ!

Бизәлгән табыннар,
Җыелган кунаклар,
Бүген туй, бүген туй, бүген туй.
Кавыша яшь парлар,
Багышлыйбыз җырлар,
Гел сезнең хакта ла безнең уй.
    Шауласын-гөрләсен,
    Күз генә тимәсен,
    Бәхетле булыгыз, булыгыз...
    Кияү һәм дә кәләш,
    Изге теләк, киңәш,
    Уң булсын, уң булсын юлыгыз!
Кавышкан көнегез,
Шатлыклы йөзегез,
Сез бергә гомергә бүгеннән.
Тылсымлы мәхәббәт,
Ярату һәм сөю,
Китмәсен күңелдән, күңелдән.
    Бәхетле булыгыз,
    Бәхетле булыгыз,
    Нык булсын гаиләнең нигезе.
    Насыйп булсын сезгә
    Гомернең буена
    Тормышларның парлы, тигезе.

## 11. «ӘНИ» ДИП ЙӨРӘККӘ ЯЗЫЛГАН

Кешелекне дәвам иттерүче
Ул безнең кадерле әниләр.
Изге зат, изге җан җир йөзендә,
Фәрештәгә сезне тиңлиләр.

Бөекләрдән-бөек, иң матур сүз –
«Әни» дип йөрәккә язылган.
Мәрхәмәтле булган шушы хисләр
Ул безнең җаннарга салынган.

Шәфкатьле, бердәнбер олы йөрәк
Ул синдә, тик синдә, әнием.
Моң булып агыла җаннарымнан
Хөрмәт хисем, олы сөюем.

Сәламәтлек, озын гомерләрне
Телим сиңа таңнар атканда.
Тәрәзләрдә утың һич сүнмәсен,
Яннарыңа саг(ы)нып кайтканда.

## 12. СҮЗЛӘРЕҢ ДӘВА

Иң матуры, иң чибәр һәм гүзәл,
Әнием, бәгырем, кадерлем.
Без дә шулай, әниләр өчен лә,
Өзелгәне бит лә бәгырьнең.

Яз кояшы кебек, әни, йөзең,
Иркә җилдәй синең сулышың.
Үзе дәва була җаннарыма
«Балам» дигән назлы тавышың.

Хыялларга очар канат бирдең,
Исән-сау гына бул, әнием.
Киңәшергә кирәк чакларымда,
Әл(е) дә ярый син бар, диюем.

Күңел һаман бала чакка кайта,
Синең яннан килми китәсем.
Килә, әнием, синең белән генә
Бер шатлыкны ике итәсем.

## 13. РӘХМӘТ ӘТИ, РӘХМӘТ ӘНИ

*(Кияү-кәләшнең туйда әти-әниләренә рәхмәт сүзе)*

Артта калды барсы-барсы,
Балачак, үсмер чаклар.
Егет-кыз булган вакытлар,
Ваемсыз булган чаклар.

Бүген бәхетле көнебез,
Без бүген кәләш-кияү.
Рәхмәт әти-әни, дибез
Чын күңелдән без икәү.

Булыштыгыз, тырыштыгыз,
Кеше булсын, дидегез.
Безнең өчен бик кадерле
Безгә сезнең икегез.

Тормышка аяк басканда,
Киңәшегез бик кирәк.
Тоеп бәхет-куанычны,
Типсен лә сезнең йөрәк!

## 14. СЕЗ ҺАМАН МИҢА КИРӘК

Әти-әни – пар канат,
Очарга алга карап.
Озатасыз олы юлга,
Якты киләчәк юрап.

Сез һаман миңа кирәк,
Сездә ул олы йөрәк.
Мәрхәмәтле изге күңел,
Тормышымда сез кирәк.

Зур өметләр баглыйсыз,
Чын кеше булсын, дисез.
Кайчан гына карасаң да,
Гел яхшылык телисез.

Әнием – якты кояш
Тормышымның күгендә.
Әти киңәше кирәк, дип
Кабатлыймын бүген дә.

## 15. ӘНИЕМ КӨТӘ

Җәйләр җитсә, уйсу болыннарда
Җиләк җыя минем әнием.
Иңнәренә ал яулыгы төшкән,
Бигрәкләр килешә, диюем.

Җиләк тәме, гөлле җәйләр яме
Төшләремә кереп йөдәтә.
Кайтыйм тизрәк туган якларыма,
Сагыныплар әнием көтә.

Җәйләр ямьле җиләкләре белән,
Гел җәй теләр идем, яраса.
Җиләк чәе бигрәк тәмле була,
Әле аны әнием ясаса.

Җиләк кагы һәм дә кайнатмасы
Һәрвакытта табын түрендә...
Әнием минем, иң кадерле кешем,
Син һәрвакыт минем йөрәк түремдә!

## 16. ИСӘНЛЕГЕҢ КЫЙММӘТ БАРЫННАН

*(Әнием)*

Гомерем буена, сыенып куеныңа,
Килә бала булып каласым.
Әнием лә, диеп, башларымны иеп,
Күзләреңә килә багасым.

Әниемнең җыры, йөрәктәге моңы
Ташып чыккан күңел ярыннан.
Тыңлыйм хәйран калып,
җаннарыма салып,
Исәнлегең кыйммәт барыннан.

Күңелеңдә назлар, әйтерсең лә язлар
Сабый чакка мине кайтара.
Ярдәм итеп безгә, безнең һәммәбезгә,
Өлгерәсең икән кай ара.

Әнием бергенәм, елмай да көл генә,
Йөзләреңнән нурлар түгелсен.
Килер яшәр еллар, үтәр озын юллар
Бәхет-шатлыкларга күмелсен!

## 17. ӘНИЕМНЕҢ НАЗЛЫ КҮҢЕЛЕ

Бар көчеңне, йөрәк җылың биреп,
Кадерләп-кадерләп үстердең.
Һәрвакытта безнең теләкләрне –
Барысын да якын, үз күрдең.

Синең караш язлардан да якты,
Синең сүзләр – йомшак таң җиле.
Үзе шәфкать, үзе дәва бит ул
Әниемнең назлы күңеле.

Әл(е) дә ярый син бар дөньяларда,
Әл(е) дә ярый, әнием, син бар.
Яшәдең син безнең өчен диеп,
Бездә булды бөтен игътибар.

Бу җырымны сиңа багышладым,
Күмелепләр яшә бәхеттә,
Озын гомер, сәламәтлек белән,
Гомер буе шатлык-рәхәттә!

## 18. ТӨШЛӘРЕМДӘ ЮАТ, ӘНИЕМ

Иртә киттең, кире кайтмас җиргә,
Бик сагынам әнием кадерлем.
Көн туды исә, сине сагынудан
Өзгәләнә җаным, бәгырем.

Төшләремдә генә булса да
Кайтып юат мине, әнием.
Искә алып әйткән сүзләрем
Дога булсын сиңа, диюем.

Барыбызга әни бик кирәк,
Олыгайган чагың булса да.
Гаиләң булып, хәтта тормышыңда
Бәхетләрең көлеп торса да.

Тормыш кад(е)рен белеп яшәдең син,
Кояш кебек иде йөзләрең.
Колагыма һаман ишетелә
«Балам» диеп әйткән сүзләрең.

## 19. СИН КАЙДА ИДЕҢ, ӘТИЕМ

Кайларга китеп югалдың,
Нинди иде уйларың?
Безне ташлап, бездән китеп
Булды йөрер юлларың.

Син кайда идең, әтием,
Тәпи атлап киткәндә?
Тәрәзләрдән күзне алмый
Өзелеп-өзелеп көткәндә?

Әтине сайлап алмыйлар,
Ник таш булды йөрәгең?
Белмәдеңме бала өчен
Җирдә әти кирәген?

Рәхмәтем зур әниемә,
Олы юлга чыгарды.
Гомер буе «әни» сүзен
Мин тотармын югары.

## 20. ӘТИЕМНЕҢ ТУГАН КӨНЕ

Әтиемнең туган көне,
Күңелем тулы шатлык.
Телимен чын күңелемнән
Тазалык, саулык, байлык.

Бүген синең туган көнең,
Якты гомер бәйрәмең.
Кабул ит, әтием, бездән
Матур теләк бәйләмен!

Озын булсын гомерләрең,
Үтсен көнең рәхәттә,
Алга карап яшә еллар
Тынычлык, бәрәкәттә!

Еллар үтә дип уфтанма,
Синең иң матур чагың.
Үткәрикче бәйрәмнәрне
Бергәләп тагын, тагын!

## 21. ӘНИЕМ, СИНЕ ЗУРЛЫЙБЫЗ

Бүген бит гомер бәйрәмең –
Дулкынланып син көткән.
Туган көнең – юбилееӊ,
Күпме гомерләр үткән.

Теләп-теләп теләкләрне,
Барсын сиңа юллыйбыз.
Олы хөрмәт хисе белән,
Әнием, сине зурлыйбыз.

Фәрештәгә тиң гүзәл зат,
Безнең өчен горурлык.
Соклandыра барыбызны
Синдә булган сабырлык.

Кешелекле, уңган-булган,
Син безгә бик кадерле.
Шатлык белән уздырыйк ла
Шул кадерле гомерне!

## 22. «ӘТИ» ДИЕП ӘЙТӘ АЛМАДЫМ

Әти-әниемнең урыны
Йөрәк түрендә бит, янәшә.
Безнең белән инде булмасаң да,
Күңел һаман «әти» дип дәшә...

Эндәшәсем килгән чакларда да,
«Әти» диеп әйтә алмадым.
Шушы хисне гом(е)рем буйларына
Йөрәк түрләрендә саклармын.

Беркемгә дә һәм дә беркайчан да
Әтисез калырга язмасын...
«Әти» диеп эндәшәсе килү
Сагыш булып җанда калмасын!

Бала өчен әти һәрчак кирәк,
Киңәшләре, әйтер сүзләре.
Озын гомер бирсен әтиләргә,
Якты булсын тормыш көзләре!

## 23. ӘТИ-ӘНИЕМӘ

Әти-әни җирдә иң кадерле,
Якын була бит ул балага.
Ана күң(е)ле булса да балада,
Бала күң(е)ле, диләр, далада.

Ләкин инде нәрсә дисәләр дә,
Минем өчен алар бик кирәк.
Бәхет-шатлык һәм дә куанычта
Бергә типсен сезнең пар йөрәк.

Минем өчен сез бит пар канатлар,
Иңләр өчен тормыш күкләрен.
Күпме генә сөйләп аңлатсам да,
Әйтеп бетерә алмам сүзләрем.

Яныгызга шундый саг(ы)нып кайтам,
Минем бәхет – минем гаиләм.
«Әти-әни» диеп эндәшүләр –
Үзе шатлык, үзе бер бәйрәм.

## 24. ТУГАН КӨНЕҢ – ЮБИЛЕЕҢ БЕЛӘН, ӘНИЕМ!

Әнием, җаныем, кадерлем,
Өзелгәне безнең бәгырьнең.
Исән булып яшә шатланып,
Килер көннәреңә куанып.

Сәламәтлек, саулык-бәхеттә
Яшә әле, әнием, рәхәттә.
Сиңа атап язган җырыбыз,
Кушылалар кече-олыбыз.

Балаларың – синең шатлыгың,
Сүнмәс өмет, күңел аклыгың.
Кояш булып тормыш күгендә
Балкыйсың син менә бүген дә.

Юбилееӊ – синең бәйрәмең,
Кабул итче теләк бәйләмен.
Олы хөрмәт сиңа, мәдхия,
Синең алда бар(ы)быз баш ия.

## 25. ИСӘН ГЕНӘ БУЛ, ӘНИЕМ

Мин кайттым дип сөенәсең,
Йөгереп табын көйлисең.
Утыр, әни, ял ит бераз,
Сүзләрем күп сөйлисем.

Иртәгә тагын китәргә,
Китим генә ничекләр?
Исән генә бул, әнием,
Ачык булсын ишекләр.

Бик сагындым әнием лә,
Сыйпа әле чәчемнән.
Гел янымда тотар идем,
Әгәр килсә көчемнән.

Юк, дисең бит, китмим, дисең,
Яшим, дисең, өемдә.
Шушы йортта, шушы нигез,
Үз тормышым-көемдә.

## 26. БӘЙРӘМ БУЛСЫН ҺӘР КӨНЕГЕЗ

*(Әти-әнием)*

Еллар уза аккан сулар кебек,
Һич туктатып булмый вакытны.
Өеп бирсен Ходай икегезгә
Сәламәтлек белән шатлыкны.

Әти-әни, һәрвакытта, диям,
Бәйрәм булсын яшәр көнегез.
Тормыш күге һәрчак аяз булсын,
Чәчәк атсын бәхет гөлегез.

Безнең өчен син кадерле, әни,
Изгелектә синең күңелең.
Хезмәт белән, намус белән яшәү,
Беләм, әти, ансат түгелен.

Картаймагыз, бер дә картаймагыз,
Яшәү нуры булсын йөзләрдә.
Олы рәхмәт хисен белдерәмен
Чын йөрәктән әйткән сүзләрдә.

## 27. ӘТИ-ӘНИ ФАТИХАСЫ

Йөгереп йөргән тугайларым,
Истә чишмә буйлары.
Сәлам булсын сезнең өчен
Минем сагыну җырлары.

Сабый чаклар, үсмер чаклар –
Гөрләп үскән чаклар ул.
Әти-әни фатихасы –
Тормышыма якты юл.

Бик сагынам авылымны,
Туган якның болынын.
Мине уйнарга өйрәткән
Әтиемнең гармунын.

Рәхмәт, диям чын күңелдән,
Әти-әнием, сезгә.
Чын тәрбияне биргәнсез
Бәләкәй чактан безгә.

## 28.СИНЕҢ КЕБЕК ЯШИ АЛСАМ

*(Әнием)*

Үстерден, әни, кадерләп,
Иркәләп, кызым, диеп.
Матур яшәү серләренә
Төшендереп һәм сөеп.

Мин тырышам тормышымда
Әниемә охшарга.
Бәхетле булып язмышта,
Бәхет кошын тотарга.

Мин яшәрмен бары сиңа
Тик куанычлар булып.
Миңа карап, күңел түрең
Торсын шатлыкка тулып...

Бик бәхетле булып яшәү –
Минем матур теләгем.
Яшәү гүзәллеген тоеп,
Армый типсен йөрәгем...

## 29. СӨЙЛӘШИК ӘЛЕ, ӘНИЕМ

Сөйләш әле минем белән
Бала чактагы кебек.
Китсен күңелең яктырып,
Торсын йөзләрең көлеп.

Сөйләш әле минем белән,
Сөйләшү – җанга рәхәт.
Мине аңлап торганыңа,
Барсына, әнием, рәхмәт!

Тулып ташыган күңелләр
Түгелә синең янда.
Синең иркә карашыңда
Мин бит сабый һаман да.

Канатлар үскәндәй була,
Иңнәремә кагылсаң.
Хәбәр ит – йөгереп кайтам,
Әни, мине сагынсаң.

## 30. ИСӘН-САУ ГЫНА БУЛЫГЫЗ!

*(Әти-әнием)*

Әти-әни – яшәү нуры,
Әти-әни – пар канат.
Сездә булган яхшылыкны
Бетереп булмас санап.

Исән-сау гына булыгыз,
Тигез гомер итегез.
Безнең өчен бик тә якын
Һәм кадерле икегез.

Сөйләшергә, киңәшергә,
Сезнең янга киләбез.
Һәрчак сезнең сүзегезнең
Кирәклеген беләбез.

«Әткәй-әнкәй» диеп, сезгә
Бик кадерләп дәшәбез.
Сәламәтлек, бәхет белән
Йөзгә кадәр яшәгез!

## 31. ӘТКӘЙ-ӘНКӘЙГӘ РӘХМӘТ!

Теләк теләп чын йөрәктән,
Сөенеп безнең өчен,
Әткәй-әнкәй, сез яшисез,
Арттырып яшәү көчен.

Без кайтканда, һәрвакытта
Табын тулы сый-нигъмәт.
Әткәй-әнкәй, барсы өчен,
Сезгә бездән зур рәхмәт!

Күңел түре ул буш түгел,
Төрле вакытлар була.
Күңелдәге бар борчулар
Сезнең янда он(ы)тыла.

Сәламәтлек, озын гомер,
Куанычлар һәм шатлык,
Язсын сезнең икегезгә
Парлы, бәхетле картлык.

## 32. РӘХМӘТ ӘТКӘЙ-ӘНКӘЙГӘ!

Олы йөрәк, киңәш сүзләр,
Ул һәрвакыт – эткәем.
Өй җылысы, өйнең нуры,
Ан(ы)сы менә – әнкәем.

Рәхмәт, рәхмәт барсы өчен
Газиз әткәй-әнкәйгә.
Олы хөрмәтемне кушам,
«Рәхмәт» сүзен әйткәндә.

Без кайтканда өйдә – бәйрәм,
Он(ы)тыла бар мәшәкать.
Әткәй-әнкәй, сезнең янда
Бергә булулар рәхәт.

Гомер буе һәрчак сезне
Бик кадерләп яшәрбез.
Саулык-сәламәтлек белән
Исән-имин яшәгез!

## 33. УТЫР, ӘНИЕМ, СӨЙЛӘШИК...

Кайттым, әни, сагынып,
Коштай канат кагынып.
Бик озак күрми торганга,
Саг(ы)ну шәлен ябынып.

Утыр, әни, сөйләшик,
Күгәрчендәй гөрләшик.
Салып урталарга барсын,
Серләшик шул, серләшик.

Синең дә бар сүзләрең,
Моңсуланган йөзләрең.
Менә шуңа сөйләгәндә
Яшьләнә бит күзләрең.

Китмим синнән озакка,
Сакла, үзеңне сакла.
Китү-кайтулар арасы
Биг(е)рәкләр озак ла.

## 34. УТЫР ӘЛЕ, ӘНИ, ЯННАРЫМА

Күпкә түгел, сине күрер өчен
Кайттым, әни, кайттым бик азга.
Килче әле, утыр яннарыма,
Эшләреңне куй да беразга.

Утыр әле, әни, яннарыма,
Утыр әле, утыр, сөйләшик.
Искә алып сабый чакларымны
Элеккечә әйдә серләшик.

Утыр әле, әни, яннарыма,
Сөйләр сүзләр бик күп җыелган.
Сабый чакның якты мизгелләре
Йөрәк түрләренә уелган.

Килче әле, әни, яннарыма,
Сөйләшепләр тагын утырыйк.
Үткәннәргә кайтып, әйдә тагын
Әнә шулай, шулай онтылыйк.

## 35. АК ТЕЛӘК

Бала өчен әни ул – тормыш,
Якты дөнья бүләк итүче.
Олы юлга сине озатып,
Кайтуыңны өзелеп көтүче.

Синең сүзең – миңа ак теләк,
Киткән чакта каласың теләп.
Әнием лә, назлы карашың,
Әйтер сүзең миңа бик кирәк.

Изге уең, хәер-фатихаң
Юлларда хәвефсез йөр(е)тә.
Тәмле ашың, өйне сагынып
Үтә, әни, гомерләр үтә.

Бар нәрсәдән кыйммәт-кадерле
Әниемнең исән-саулыгы.
Менә шушы, шушы була инде
Бәяләнмәс гомер байлыгы.

## 36. ЫШАН, ӘНИЕМ

Балам, диеп назлап-иркәләп,
Кыенлык китерми үстерден.
Һәрбер теләк, адым-уйларны
Йөрәгенә алып, үз күрдең.

Ышан, әнием, ышан сүземә,
Авырлык китермәм үзеңә.
Бары шатлык нурлары гына
Балкып торыр синең йөзеңдә.

Синең йөрәк – үзе мәрхәмәт,
Әнием-бәгърем, сиңа мең теләк:
Мәңге яшә күм(е)леп бәхеткә,
Син, әнием, миңа бик кирәк!

Гүзәл, чибәр, уңган, булдыклы,
Бирсен Ходай озын гомерне.
Син кояшы күңел күгемнең,
Син, әнием, бик тә кадерле.

## 37. БИК САГЫНАМ, ӘНИЕМ

Бигрәк кыска булды гомерең,
Нурлы булсын, әнием, кабереӊ.
Безне иртә ташлап киткәнгә
Өзеләдер минем бәгырем.

Сагынам, шулкадәр сагынам,
Җанда сагыш уты кабынган.
Әниемнеӊ якты истәлеге
Яшьле күзләремә ягылган.

Ышанасы килми киткәнгә,
Синсез, синсез гомер иткәнгә.
Бигрәк авыр үтә вакытлар,
Күңел һаман сине көткәнгә.

Дога булсын әйткән һәр сүзем,
Күз алдымда елмайган йөзеӊ.
Төшләремә кергән чакларда
Өйрәт, әни, булырга түзем.

## 38. САГЫНДЫМ, ӘНИЕМ

Ур(ы)ның йөрәк түрендә,
Син һаман да күңелдә.
Коштай очып кайтыр идем
Яннарыңа бүген дә.

Әнием лә, сагындым,
Сагындым, бик сагындым.
Кайтыр юлларыма карап,
Әллә ничә талпындым.

Син көтәсең – мин беләм,
Мин дә төшемдә күрәм.
Төшләремдә күрешәм, дип,
Гел каршыңа йөгерәм.

Әни якын, бик якын,
Аңлатырга җитми сүз.
Бәхет-шатлык нурларыннан
Балкып торсын синең йөз.

## 39. МАТУР ПАР

*(Әти-әнигә багышлап)*

«Бәхетле пар, матур парлар» дигән
Сүзләр йөри халык телендә.
Сезгә карап, бар(ы)быз сокланабыз,
Шатланабыз менә бүген дә.

Җитәкләшеп, бергә гомер итеп,
Әйтер сүзне аңлап караштан,
Матур парлар булып яшәр өчен,
Ходай сезне үзе яраткан...

Саф хисләрдән туа саф мәхәббәт
Гомер буйларына җитәрлек.
Сөеп һәм сөелеп яшәгәндә,
Язмышларны гөлләр итәрлек.

Олы хөрмәт сезнең икегезгә,
Җырлыйм сезгә олы мәдхия.
Барсы-барсы өчен рәхмәт әйтеп,
Барыбыз да сезгә баш ия.

## 40. ОНЫТМАГЫЗ ӘТИ-ӘНИЛӘРНЕ!

Сулар сипми, гөлегезне,
Онытып, корытмагыз.
Әтиләрне, әниләрне
Һичкайчан онытмагыз!
Онытмагыз, онытмагыз,
Еракта булсагыз да.
Мәшәкатьләр, эшләр белән
Күмелеп калсагыз да...

Көттермик әтиләрне,
Елатмыйк әниләрне.
Дөнья куган булып, һич тә
Югалтмыйк кадерләрне.
Алар бит безне көтәләр,
Күзләре гел юлларда.
Бала бәгырь һәрвакытта
Йөрәктә дә уйларда...
Картлык килә һәр кешегә,
Дөнья шулай яралган.
Ә бит саг(ы)ну дигән уйлар
Шул сагышка уралган.

## 41. АНА КӨТӘ СОЛДАТ УЛЫН

Ана көтә солдат улын,
Ил чигендә баласы.
Әйләнеп кайт исән-имин,
Булма йөрәк ярасы.

Гел синең белән күңел,
Багалмам, солдат улым.
Кайда хезмәт итсәң дә син,
Турыдан булсын юлың.

Төн йокысы һәрчак уяу,
Уйлый ана баласын.
Усалларны очратудан
Ходай үзе сакласын.

Безнең өчен сез бит сакта,
Ватанны саклаучылар.
Аяз булсын күк йөзе, дип,
Сез безне яклаучылар.

## 42. ШАТЛАНДЫРЫЙМ НИЧЕК?

Бу исемдә күпме ягымлылык,
Бу сүздә, дим, күпме иркә-наз.
Түземлелек һәм дә олы йөрәк –
Гөлчәчәкле, шаулы якты яз.

Әниемнең туган көне җиткән,
Шатландырыйм икән ничек, дим.
Нәрсә генә эзләп сайласам да,
Синең сабырлыкка булмас тиң.

Бар җиһанның яхшылыгы сыйган
Әниләрнең йөрәк түренә.
Яшисе иде бары сөендереп,
Китермичә хәсрәт күң(е)леңә.

Миңа яшәү, тормыш бүләк иткән,
Син, әнием, бер дә кайгырма:
Балаларың горурлыгың булыр,
Безнең өчен һич тә картайма.

## 43. ЯРАТАМ ӘНИЕМНЕ

*(Балаларга)*

«Балам» диеп назлап дәшеп
Үстерәсең иркәләп.
Киңәшләрең бирә-бирә,
Зур тормышка әзерләп.

Иң кадерле кешем булган –
Яратам әниемне.
Чәчләремнән сыйпап-сыйпап,
«Кадерлем» диюеңне.

Тик син генә матур итеп
Иркә сүзләр сөйлисең.
Иң арыган чакларымда
Җырлар җырлап көйлисең.

Менә тиздән зур үсәрмен,
Сиңа терәк булырмын.
Синең барлык эшләреңә
Ярдәм итеп торырмын.

## 44. РӘХМӘТ, ӘТИЕМ!

Әнием белән һәрчак янәшәмдә –
Әтиемә мин зур рәхмәтле.
Бар кешегә шуны теләр идем,
Бирсен, диеп, тигез бәхетне.

Горурлыгым минем тормышымда,
Таянычым һәм дә ярдәмчем.
Рәхмәт сиңа барсы өчен, әти,
Һәрвакытта син бит киңәшчем!

Зур юлларга мине алып чыктың,
Аңлыйсың син барсын-барсын да.
Изгелегең, яхшылыгың өчен
Ниләр эшлим икән тагын да?

Озак яшә әнием белән бергә,
Тормыш матур, дөнья киң бит ул!
Үрелеп барсын бәхет-шатлыкларга,
Ачык булсын безнең барган юл!

## 45. ӘНИЕМӘ

Йөрәк түрем, күңелемнән чыккан
Бу җырымны сиңа язамын.
Олайсам да, киңәшергә диеп,
Яннарыңа синең барамын.

Ихлас сүзе белән юатучы
Әнием, әнием, әнием.
Яшәү көче биреп яшәтүче,
Бердәнбер ул, син ул, диюем.

Карашларың иркә назлы җилдәй,
Өшегән җанны да терелтә.
Чын йөрәктән чыккан догаларың
Зур юлларда саклап йөр(е)тә.

Җир йөзендә әни күң(е)ле кебек
Бернәрсә юк нурлы һәм якты.
«Балам» диеп өзгәләнгән җаның
Иң олы хөрмәткә бит хаклы!

## 46. ЯШӘГЕЗ ШАТЛЫКТА

Яныгызга сагыныплар кайтам,
Әти-әни, тату гаиләм.
«Кызым» диеп күтеп алуыгыз –
Үзе шатлык, үзе бер бәйрәм...

Кайгы күрми, хәсрәт белми генә
Яшәгез лә муллык-байлыкта.
Озын гомер, сәламәтлек белән,
Матур тормыш һәм дә шатлыкта.

«Балам» диеп назлап үстердегез,
Озаттыгыз озын юлларга.
Бәхетләрнең нуры гына яусын
Гомер дигән сезнең елларга...

Һәрвакытта әйткән сүзләрегез,
Киңәшегез бик тә, бик кирәк.
Минем өчен куанып-сөенеп
Типсен иде сезнең пар йөрәк...

## 47. БИК КАДЕРЛЕ СЕЗ МИҢА

Минем өчен җирдә
Иң кадерле булган
Ул бит, ул бит – әти-әнием.
Гомер, тормыш, бәхет,
Шатлык бүләк иткән
Изге җаннар – сез ул, диюем...

Рәхмәт сезгә, рәхмәт
Барсы-барсы өчен:
Дөнья матурлыгын биргәнгә,
Җил-яңгыр тидерми
Иркәләп һәм сөеп,
Күңел назларына төргәнгә...

Сезнең теләк, акыл,
Матур сүзләр, киңәш –
Алар кирәк тормыш юлында.
Ышаныч һәм ярдәм
Кирәк булган чакта,
Сезнең куллар минем кулымда.

Мин бик тә бәхетле
Минем янәшәмдә

Шундый әти-әни булганга,
Сезнең барлыгыгыз
Минем киләчәккә
Якты маяк булып торганга.

Озын гомер сезгә,
Саулык-сәламәтлек,
Тигез генә гомер итегез!
Кайтарасым килә
Барлык яхшылыкны,
Бик кадерле миңа икегез.

## 48. ӘТИЕМНЕ КӨТӘ ӘНИЕМ

Кайтырсың күк менә
Бер дә көтмәгәндә,
Ачып керерсең дә ишекне.
Күпме генә көтеп,
Көтеп тилмерсәк тә
Табалмабыз синең кебекне.

Бигрәк иртә киттең,
Безне ятим иттең,
Сагынабыз сине, әтием.
Менә кайтыр, диеп,
Күзен алмый көтә,
Өзелепләр көтә әнием.

Ышанасы килми
Синең юклыгыңа,
Кыска булды, әтием, гомерең.
Моң-сагышка чумган
Әниемне күреп,
Әй өзелә, өзелә бәгырем.

Җитмәс кебек сүзләр
Әйтеп аңлатырга

Кичерешләр тулы йөрәкне.
Ниләр генә әйтеп,
Ничек җиткерим соң
Син һаман да безгә кирәкне?!

## 49. ӘНИЕМӘ

Җир йөзендә әнидән дә якын
Тагын кемне әйтә аласың?
Бар нәрсәдән артык күреп, ана
Ярата ул газиз баласын!

Озын гомер, сәламәтлек бирсен,
Якты булсын, ән(и)ем, көннәрең.
Рәхәт тормыш телим һәрчак сиңа,
Сулмасыннар бәхет гөлләрең.

Тырыш булдың, әни, гомер буе,
Сабыр булдың, олы йөрәкле.
Һәр адымда, һәрбер сулышымда
Тоеп яшим синең кирәкне.

Әни, әни! Бары синдә генә
Чишмәләрдәй чиста, ак күңел.
Шатлык-бәхет нуры булып гел дә
Яктыртасың тормышның күген.

## 50. РӘХМӘТ, ӘНИЕМ!

Чибәрләрдән-чибәр безнең әни,
Изгеләрдән-изге һәм уңган.
Газизләрдән-газиз, ягымлы йөз,
Бар эшкә дә уңган ул, булган.

«Әни» диеп, барсы-барсы өчен
Рәхмәт әйтә синең кызларың.
Ике кызың – ике бәгырькәең,
Тормыш күгендәге йолдызларың.

Балаларга диеп багышладың
Тормышыңны, көнең-төнеңне.
Инде менә, хөрмәт итеп, бүген
Кадерлиләр синең үзеңне.

Әни назы – үзе мең-мең шифа,
Әни сүзе – яздай бер тылсым.
Алиһәдәй гүзәл әниебез,
Яшәр гомерләрең (о)зын булсын!

Сәламәтлек, тыныч тормыш сиңа,
Озын булсын, әни, гомерең!

Еллар узган саен, гел дә шулай
Арта гына барсын гомерең.

Мул тормышта шатлыкларга күм(е)леп,
Куанычта яшә, рәхәттә,
Гөрләп кенә, балаларың белән
Сөенечтә һәм дә бәхеттә.

## 51. МӘҢГЕ ЯШЬ КАЛ, ӘНИЕМ

Гомер биргән, яшәү көче биргән –
Әнием, әнием, кадерлем.
Миңа терәк һәрвакытта кирәк,
Өзелгәне минем бәгырьнең.

Мәңге яшь бул, картаймале бер дә,
Нурдай балкып торсын йөзләрең.
Үзе дәва, үзе дога бит ул
Чын йөрәктән әйткән сүзләрең.

Ягымлы да, гел дә кунакчыл син,
Күңелеңдә синең изгелек.
Гаиләнең сүнмәс кояшы син,
Без яшибез шуңа гөр килеп.

Әнием, дип, һәрчак шатланамын,
Тулы бәхет ул син булганда,
Барыр юлым, хыял-өметләргә
Яшәү дәрте биреп торганда.

## 52. АНА ЙӨРӘГЕ

Әниләрнең җирдә бөеклеген
Аңлатырга сүзләр җитмидер.
Алар өчен булган хөрмәт хисе
Күңелләрдән бер дә китмидер.

Бар җиһанның изгелеге сыйган,
Мәрхәмәтле ана йөрәге
Хәсрәтләрдән тетрәнмәсен, зинһар,
Бу – һәркемнең изге теләге.

Һәр кешенең газиз анасы бар,
Ана күң(е)ле – үнмәс яктылык.
«Балам» диеп гомер кичерәсез,
Йөрәгегез тулы яхшылык.

Сүзләрегез – хәер-фатихадай,
Гомер буе саклап йөр(е)тә.
Ана йөрәгенең кайнарлыгы
Ташларны да хәтта эретә.

## 53. МЕҢ-МЕҢ РӘХМӘТ!

*(Әнием)*

Тереклек, кешелек бүләк иткән,
Җир йөзендә тиңнәр юк аңа.
Бердәнбер, кадерле булган кеше
Ул – безнең әниләр, ул – ана.

Әниләр күңеле – тирән дәрья,
Әниләр йөрәге – мәрхәмәт.
Изге зат булган бу аналарга
Мең рәхмәт, мең рәхмәт, мең рәхмәт!

Ул – кояш күңелнең күкләрендә,
Гөлбакча йөрәкнең түрендә.
Елмаеп әйтелгән һәрбер сүзе
Нур булып балкый ла күңелдә.

Балам, диеп, һаман талпына ул,
Балам, диеп ала сулышын.
Газизенә багышлый ул ана
Үзенә язылган язмышын!

# ДҮРТЬЮЛЛЫКЛАР

Барыбызга син кадерле,
Телибез изге теләк.
Синең бәхетле булуың
Безнең өчен бик кирәк!

***

Синең йөргән юлларыңа
Бәхетләр яуса иде.
Туган көнең шатлык булып
Күңелдә калса иде.

***

Яшә шатлык-куанычта,
Килер елларга карап.
Бәхет килсә килә бит ул,
Тормый ла синнән сорап.

***

Матур-матур теләкләрне
Юллыйбыз чын күңелдән.
Бәхет нурлары китмәсен
Мәхәббәтле йөзеңнән.

***

Син бик кирәк, безгә кирәк,
Аңласаң иде шуны.
Мондый матур бәйрәмнәрнең
Түгел бит әле соңы.

Очрашырга язсын кабат
Шатлыкта-куанычта.
Синең булуың безгә бит
Бәхет тә, юаныч та.

Рәхмәт сиңа барсы өчен,
Бик тә хөрмәт итәбез.
Инде хәзер үзеңне дә
Без кунакка көтәбез.

***

Кирәк синең елмаюың,
Кирәк матур сүзләрең.
Беркайчан да моңаймасын
Ай-кояштай йөзләрең.

Кирәк синең киңәшләрең,
Кирәк янда булуың.
Безнең күңелләребезгә
Шатлык булып тулуың.

***

Һәрвакытта яшь, чибәр бул,
Көлеп торсын йөзләрең.
Бүгенгедәй булсаң әгәр,
Килмәс гомер көзләрең.

Өмет-хыял булган чакта,
Ник моңаеп яшәргә?
Без бит тиеш бергә-бергә
Яшеннәрдәй яшьнәргә!

Бергә булыйк, бердәм булыйк,
Барыр юлыбыз – бергә.
Гел дә шулай шатлык белән
Яшәекче гомергә.

***

Тамчылардан күл җыела,
Барладың барсын үзең.
Нинди генә кыен булсын,
Булдың барсына түзем.

Үрнәк булып яшисең син,
Булдырасың барсын да.
Ярдәмчел, гадел һәм үткен
Барыбыз арасында.

Сиңа карап сөенәбез,
Яшә, дибез, гел шулай.
Бәхет-шатлык, куанычта,
Эшләрең барсын уңай.

***

Табыннарың түгәрәк,
Бәйрәмнәрең мөбарәк.
Гел дә шулай якын булып,
Яшик бергә-бергәләп.

Балаларың янында,
Сөйгән ярың янында.
Игътибар, назга күмелеп
Яшә тагын, тагын да.

Дусларыңа син кирәк,
Якыннарга син кирәк.
Парлы матур гомерләрдә
Яшә булып син терәк.

***

Котлы булсын туган көнең,
Тулсын көнең шатлыкка.
Озын якты гомерләрдә
Яшә муллык-байлыкта.

Чынга ашсын теләкләрең,
Кабул булсын уйларың.
Яшә саулык-тазалыкта,
Белеп тормыш җайларын.

***

Изге сәгатьләрдә булсын,
Бүген никах көнегез.
Аклык-сафлыкка үрелсен
Мәхәббәттән күң(е)легез.

Никах сезнең йөрәкләрне
Бәйләсен лә гомергә.
Шушы көнне бәйрәм итеп
Яшәгез бергә-бергә!

***

Якты өмет-хыялыгыз
Чынга, тормышка ашсын.
Алсуланып һәр иртәдә
Бәхет таңыгыз атсын.

Кадерләп бер-берегезне,
Хөрмәт итеп, яратып,
Яшәгез барлык җиһанга
Шатлык кына таратып!

***

Яшәп булмый ялгыз гына,
Кирәк безгә якыннар.
Күңелләрнең түрләренә
Үтмәсен лә салкыннар!

***

Туган туган өчен кирәк,
Без бербөтен булыйк, димәк.
Күңелләрнең түрләреннән
Чыга бит ул шушы теләк.

Дөньяның көннәре төрле:
Бар шатлыгы, кайгысы.
Телмәсен бәгыребезне
Югалтулар ачысы.

Бергә-бергә без бит көчле,
Иңне-иңгә куйганда,
Матур уйлар белән яшәп,
Күңел җырлап торганда!

***

Мәшәкатьләр тулы тормыш,
Көн туа – шөгыль туа.
Бергәләп күңел ачулар
Күңелләргә ял була.

Бергәләшеп җыелганда,
Шатлыкларны бүлешик.
Онытмыйк дусларыбызны,
Кунакларга йөрешик.

***

Дуслар җыелган җирдә лә,
Дуслар җыелган җирдә
Уйнап-көлеп, җырлап-биеп
Яшәекче гел бергә.

Дуслар җыелган җирдә лә,
Дуслар җыелган җирдә
Әнә шулай яшәвебез
Әйләнсен гүзәл җырга!

***

Кад(е)рен белик мизгелләрнең,
Гомер бушка узмасын.
Ялгыз калып моңаерга
Бер Ходаем язмасын!

Күтәренке булсын күңел,
Гөрләсеннәр тормышлар.
Мин бит сиңа телим бары
Сәламәтлек, уңышлар.

***

Туган бар җирдә ярдәм бар,
Тормышлар бара гөрләп.
Кад(е)рен белик туганнарның,
Алар һәрвакыт кирәк.

***

Бәйрәмнәр узмый дусларсыз,
Иң якын туганнарсыз,
Матур булган теләкләрсез
Һәм дә дәртле җырларсыз.

Матур теләкләр сезгә,
Яшегез җитсен йөзгә.

Сәламәтлек, мул тормышны
Телибез үзегезгә!

***

Була бәхетле сәгатьләр
Һәм дә төрле минутлар.
Кайгы-шатлык бүлешергә
Кирәк лә якын дуслар.

Җыелганбыз икән бергә,
Шатланып күңел ачыйк.
Туганнар белән бергәләп
Гөрләшеп-җырлап яшик.

***

Алда әле күпме якты язлар! –
Узган гомерләрне санама,
Ашыкма син картаерга әле,
Җан дуслар булганда арада.

***

Гомерләр ул – бер мизгел,
Син аның кадерен бел.
Һәрбер көнең шатлык
белән,Куанычта үтсен гел.

Гомерләр узып торса да,
Үтми икән ул яшьлек.
Яшәүнең тәмен аңлыйсың,
Сүз белән булмый әйтеп...

***

Матур, чибәр, уңган, булган,
Ул – безнең әниебез.
Бәхет-шатлыкка күмелеп
Озак яшә, диябез.

Бердәнбер, якын, ягымлы,
Бергә көнебез ямьле.
Тормышларыбыз түгәрәк,
Бергә ашлар да тәмле.

Озак яшә куанычта,
Балкыплар торсын йөзең.
Безнең өчен бик тә кирәк
Синең тылсымлы сүзең.

***

Күңелнең байлыгы,
Көнемнең шатлыгы
Сез бит ул, әтием-әнием.
Янда сез булганга,
Көч биреп торганга,
Ямьле бит минем лә һәр көнем.

***

Синең йөрәк үзе мәрхәмәт,
Синең янда үзе бер рәхәт.
Барсы өчен, барсы-барсына,
Әнием лә, сиңа зур рәхмәт!

***

Әти-әнием, сезнең янда
Без кайтабыз бала чакка.
Сез исәндә, бала булып
Без бит шулай калачак та.

Исән генә булыгызчы,
Сезнең яшәү безгә кирәк!
Бергә-бергә яшәгәндә,
Без бербөтен әле, димәк.

***

Синең сүзең – акылның бит үзе,
Ходай биргән сиңа сабырлык.
Кылган гамәл, кылган
эшләреңнән,
Сокланырлык, үрнәк алырлык.

***

Балам, диеп, сөенеп елмаюың
Бар нәрсәдән кыйммәт бит миңа.
Олы хөрмәт, бәхет, сәламәтлек
Телим, әнием, телим мин сиңа.

***

Гүзәллекне миңа аңлата алдың,
Тормышымда син бер юаныч.
Барсы өчен мең-мең рәхмәт сиңа,
Синең яшәү – миңа куаныч!

***

Синең белән генә өебез ямьле,
Син – күңелнең сүнмәс кояшы.
Алга таба карап яшәгәндә
Кирәк җанга гомер юлдашы.

***

Сау-сәламәт, исән генә булыйк,
Бирсен Ходай кадерле гомер.
Тормыш тәмен, ямен белеп яшәү –
Үзе тылсым, үзе бит ул сер.

***

Һәркемнең дә җирдә үз урыны,
Борчулары, хыял, өмете.
Үзе сайлап, үзе яулап алган,
Үзе аңлаганча бәхетне.

Синең бәхет – бүгенге тормышың,
Ирешелгән һәрбер уңышың,
Үрнәк булган тату гаиләң һәм
Җырларга тиң булган язмышың.

***

Гаилә, тормыш, язмыш, бәхетләр бит
Барысы да бергә бәйләнгән.
Үткән юлың, матур киләчәгең
Бер төенгә килеп төйнәлгән.

Нәтиҗәсе аның күз алдында:
Барсы сине якын итәләр,

Рәхмәтләрне, рәхмәт сүзләрен дә
Олы хөрмәт белән әйтәләр.

***

Якыннарым, дуслар, туганнарым,
Кирәк һәрчак әйтер сүзегез,
Киңәшегез, җылы карашыгыз,
Елмаюлы якты йөзегез.

Бергә булыйк, һәрчак бергә булыйк,
Киңәш сүзләр кирәк булганда.
Тормыш гүзәл, яшәү – бәхет бит ул,
Ярдәмләшеп торганда.

***

Сулмасын тормыш гөлең,
Якты булсын күңелең.
Бәхет дулкынында үтсен
Киләчәгең, бүгенең.

***

Кояшлы булсын көнең
Һәм аяз тормыш күгең.
Шатланып матур көнеңә,
Җырлап торсын күңелең.

***

Тынычлык – өегезгә,
Куаныч – күңелегезгә,
Озын гомер, сәламәтлек
Телимен үзегезгә!

Матур парлар – тормыш күрке,
Яшәвебезнең яме.
Уртак парлы гомерләрдә
Яшәүнең бөтен тәме!

***

Яңа гаилә туган көн бу,
Кабул булсын теләкләр.
Бергә яшик, бергә булыйк,
Бергә типсен йөрәкләр.

Дуслар, туганнар җыелган,
Котлар өчен килгәннәр.
Мәңге бәхетле булсыннар
Берсен берсе сөйгәннәр.

Котлы булсын туй көнегез,
Бик бәхетле булыгыз!
Бәхет нурына күмелсен
Атлап барган юлыгыз!

***

Иң кадерле кеше бүген
Минем өчен бер генә:
Ярты сүздән дә аңлаучы
Ул бит, иркәм, син генә.

Җаныкаем-җанашым,
Сиңа төбәп карашым,
Гомер буе янәшәңдә
Килә минем барасым.

# КОТЛАУЛАР
## Икенче китап

Поздравление на татарском языке
Вторая книга

Авторы *Гөлфия Шакирова*
Төзүче *Рөстәм Сәрвәров*
Корректор *Рүзәл Мөхәммәтшин*
Компьютерда биткә салучы *Азат Низамиев*

Басарга кул куелды 27.03.2015. Форматы 60×84 $^{1}/_{32}$.
«Times» гарнитурасы. Офсет басма.
Нәшер-хисап табагы 4,0.
Тиражы 5000 данә. Заказ

ООО « Халкыбыз мирасы» нәшрияты
Казан, Спортивная урамы, 33
Тел.: 8(843) 202-3-917, 8(843) 246-2-246,
89046-746-246
www.aksu-studio.ru
сэлам.рф
e-mail: 2959308@mail.ru

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият
комплексында басылды.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.